**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге**

422008, Әтнә муниципаль районы
Түбән Шашы авылы, Молодежная
урамы, 68
тел. 3-60-38, факс 3-60-38

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Кунгерское сельское**
**поселение**

422008, Атнинский муниципальный район
д.Нижние Шаши,ул.Молодежная,68
тел. 3-60-38, факс 3-60-38

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 ноябрь 2025 ел. № 2

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елнын 21 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенә керүче Мөндеш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 21 ноябре 10.00 сәгатькә;
- үткәрү урыны – Мөндеш авылы, Зеленая урамы, 12 номерлы йорт яны;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 16 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Шашы авылы, Молодежная урамы, 68 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Мөндеш торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- гражданнар җыены турында Мөндеш торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы

(катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Авыл территориясен төзекләндерү (территорияне төзекләндерү (үләннәрне чабу, агачларны кисү, чистарту) хезмәтләр өчен түләү).
- Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу һәм Саттаров, Зеленая урамнарына түшәү, транспорт хезмәтләре һәм хезмәт өчен түләү).
- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (зиратта агачларны кисү, чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

“РИЗА” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Мөндеш авылы Зеленая урамы 12 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.
3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Рәхимҗанова Г.И .